## SÜZ BAŞI

Tatar leksikografiyäseneñ berniçä ğasır däwamında formalaşqan bay traditsiyäläre bar. Kiñräk fänni eşçänlek qısalarında ul traditsiyälär saqlana, ezlekle räweştä öyränelä häm üsterelä. Xäzerge tormış cähätennän yaqın kilep, tatarça aralaşu-añlaşu ixtıyacların tulı häm sıyfatlı itep qanäğätländerü yözennän, yañadan-yaña uqu-uqıtu äsbapları, beleşmäleklär, fänni xezmätlär dönya kürä tora, mäğlümat almaşu ölkäsendä aldıñğı texnologiyälär eşkä cigelä, İnternet çeltäre yärdämendä telebezdän faydalanu mömkinlekläre berqadär kiñäyä häm kamilläşä bara. Şuşı eşçänlek qısalarında tatar telen, anıñ leksik sistemasın tasvirlaw, süzlär xäzinäseneñ üsü-üzgärü yulların barlaw häm terkäwne küz uñında totıp, tatarça süzleklär, ayıruça tatarça-çit tel süzleklären eşläp çığaruğa da zur iğtibar birelä.

Uquçığa täqdim itelä torğan «Tatarça-inglizçä, inglizçä-tatarça süzlek» – bu yünäleştä başqarılğan yaña häm original' xezmätlärneñ berse. Süzlek Ğ. İbrahimov isem. Tel, ädäbiyat häm säñğat institutınıñ leksikografiyä bülegendä tözelde. Anıñ avtorları – filologiyä fännäre doktorı, dotsent Aynur Äxät ulı Timerxanov häm Qazan federal' universitetı ğälimäse, filologiyä fännäre kandidatı, dotsent Gölşat Rafail qızı Safiullina. Süzlek materialların kirill yazuınnan latin grafikasına küçerü programması avtorı – filologiyä fännäre kandidatı Mansur Rifqat ulı Sayhunov.

Süzlekneñ ähämiyäte anı tözügä etärgän berniçä şart belän añlatıla. Tatarstan Respublikası törle yünäleştä xalıqara xezmättäşlegen cäyelderä barğan sayın, qaysı ğına ölkäne alsaq ta, belgeçlär arasında aralaşu, täcribä urtaqlaşu arta bara. Säyäsätçelär, ğälimnär, mäğärif häm mädäniyät xezmätkärläre, biznes wäkilläre, sportçılarnıñ xalıqara kongresslar häm simpoziumnarda, säyäsi häm iqtisadi çaralarda, törle sport yarışlarında qatnaşuwı kiñräk tös ala. Çit il şirkätläre belän xezmättäşlek itü öçen yaña mömkinleklär açıla. Eçke häm xalıqara turizm üsüwen tä'min itüdä uñay şartlar tudırıla. Küpçelek oçraqta xalıqara mäydanda mondıy bağlanışlarda töp aralaşu çarası bulıp ingliz tele xezmät itä. Cir şarında milliard yarımnan kübräk keşeneñ aralaşu häm mäğlümat almaşu maqsatında näq menä şuşı teldän faydalanuwı mäğlüm. Dimäk, bügen ingliz teleneñ taralış mäydanı küpkä arta, kiñäyä bara. Bu teldä söyläşä, aralaşa alu zamança qaraşlı keşeneñ alıştırğısız sıyfatına äylänä. Şul räweşle tormış, ingliz telen belü, aña öyrätü belän bergä, ana telebez nigezendä ike yäki küptelle süzleklär äzerläw burıçın alğa sörä.

Tatar tele materialın ingliz tele yänäşäsenä quyıp tözelgän süzleklär,

ber yaqtan, tellärneñ bügenge torışın, üsü-üzgärüwen, alarnıñ tä'sir iteşüwe näticälären çağıldırsa, ikençe yaqtan, keşelärgä ber-berseneñ telen öyränü, mädäniyäte belän tanışu, anı tulıraq häm döres añlaw öçen qulay nigez bulıp tora, yäğni xäzerge wazğıyättä tulısı belän sıyfatlı aralaşuğa, xalığara mäydanda añlaşuğa xezmät itä.

Şul uq waqıtta ğlobalizatsiyä tä'sirendä xalıqlarnıñ milli yöze, lingvoetnik bilgeläre yuwılıp, yuqqa çığa barğan çorda ingliz telenä häm başqa kiñ taralğan qayber çit tellärgä tärcemä aşa üzebezneñ bay ruxi-mädäni mirasıbıznı dönya külämendä kiñräk, aktivraq propagandalaw, anıñ belän başqa xalıqlarnı da tanıştıru maqsatında mondıy tör süzleklär eşläp çığaru möhim eş yünäleşläreneñ bersen täşkil itä.

Nihayät, törle çorlarda ideologiyägä bäyle yäki başqa säbäplär arqasında nigezennän, watanınnan ayırılıp kitärgä mäcbür bulğan, dönyanıñ törle poçmaqlarına sibelep yäşägän millättäşlärebez häm alarnıñ warisları öçen dä tatarça-inglizçä süzlek bay mäğlümat çığanağı bulıp tora, aralaşuğa bulışlıq itä.

«Tatarça-inglizçä, inglizçä-tatarça süzlek» anı tözegän avtorlarnıñ küp yıllar däwamında yuğarı uqu yortlarında çit tellär uqıtu täcribäse yanına leksikografiyä ölkäsendä distä yıldan artıq alıp barğan eşçänleklären neñ näticäsen çağıldıra. Anı tözüneñ maqsatı – häm tatar, häm ingliz tellären neñ töp süzlek fondın täşkil itkän ğomumqullanıştağı leksik-frazeologik materialnı başqa telgä mömkin qadär tögäl häm añlayışlı tärcemä itü, şul uq waqıtta här ike xalıqnıñ ruxi-mädäni dönyasına bäyle mäğlümatnı mömkin bulğança kiñräk terkäp tasvirlaw. Süzlekkä xäzerge tatar häm ingliz tellärennän 25 meñgä yaqın süz häm süztezmä, 2 meñläp frazeologik berämlek terkälde.

Älege xezmätneñ asıl sıyfatı – anıñ ber üq waqıtta ike grafika nigezendä – kirillda häm latinda eşlängänlege. Süzlek rus telen belmägän, rus yazuwı belän tanış bulmağan keşelär, şul isäptän tarixi watanınnan çittä tuwıp üsep, şunda ğömer kiçerüçe millättäşlärebezneñ ber törkeme öçen dä irken qullanu yağınnan uñay häm faydalı çığanaq bulır dip kötelä.

Süzlekneñ löğätlegenä nigez itep, «Tatarça-rusça-inglizçä mäktäp süzlege» (Qazan, 2014) häm «İnglizçä-tatarça süzlek» (Qazan, 2014) alındı. Şulay uq süzlär ike telle uqu-uqıtu süzleklärendä terkälgän leksik materialğa tayanıp häm süzlärneñ qullanılu yışlığına qarap saylandı. Monnan tış här ike teldä dä kiñ faydalanılğan ğomum häm köndälek aralaşu leksikası, şul isäptän çiklängän sanda tarmaq terminnarı, şulay uq milli mädäniyät küreneşlären çağıldırğan süzlär, başqa teldä tängäle bulmağan berämleklär, yış oçrıy torğan totrıqlı ğibarälär, aktual' mäqal'-äytemnär bilgele külämdä urın aldılar. Şul uq waqıtta tatar teleneñ xäzerge üseşenä xas üzençäleklär, anıñ leksik sostavında yaña barlıqqa kilgän yäisä başqa tellärdän kerep üzläşterelgän berämleklär dä terkälde. Bu isä süzlekneñ, bigräk tä tatarça öleşeneñ löğätlegen tağın da bayıttı.

Süzlek xäzerge tatar häm ingliz leksikografiyäsendä qabul itelgän prinsıplarğa tayanıp tözelde. Bu ölkädä bulğan uñay täcribä mömkin qadär eşkä cigelde.

Süzlekne tözegendä, xäzerge tatar häm ingliz tellärendä ğämäldä bulğan

orfografiyä häm orfoepiyä normaları nigez itep alındı. Siräk kenä oçraqlarda avtorlar tege yäki bu tatar süzeneñ yazılışına üzgäreş kertüne kiräk taptı.

İngliz telendä anıñ böyekbritaniyä söyläşenä xas orfografiyägä östenlek birelde. Şul uq waqıtta süzlektä ingliz teleneñ amerika söyläşendä qullanılğan berämleklär dä urın aldı, alar maxsus bilge belän kürsätelde.

Vokabula sıyfatında terkälgän tatarça süzlärdä basım nigezdä normadan taypılış bulğan, yäğni soñğı icekkä töşmägän oçraqlarda ğına kürsätelde. İngliz telendä isä süzneñ tulı orfoepik, aksentologik tasvirlaması transkripsiyä aşa birelde.

Tatar fiğıle *-ırğa / -ergä* infinitiv şäkelendä terkälde. Ul üzeneñ funksional'-semantik kürsätkeçläre belän ingliz telendäge infinitivqa turı kilä. Küp kenä tatarça fiğıl'lär, bigräk tä tezmä törenä qarağannarı, ingliz telendä tege yäki bu fiğıl' belän bäyläneştä ayırım ber mäğnäne beldergändä genä qullanıla torğan bäyleklär belän birelde.

Nigezdä ingliz fiğıle başlanğıç infinitiv formasında mäqalä eçendä *to* kisäkçäse belän qullanıldı.

Här ike teldä dä fiğıl'neñ yünäleş, ayırım oçraqlarda zatlanışsız formaları leksik mäğnä beldergändä genä vokabula itep terkälde.

Şulay uq häm tatar, häm ingliz telenä xas konversiyä küreneşe, yäğni ber süzneñ ikençe ber süz törkemenä qarağan berämlek sıyfatında qullanılu mömkinlege isäpkä alındı.

Şaqmaq bilgesennän soñ (□) alfavit tärtibendä tärcemäläre belän komponentları ayırım yazılğan tezmä süzlär häm totrıqlı ğibarälärgä yaqın torğan süztezmä berämleklär kiterelde.

Tatar yäki ingliz telendä täñgälläre bulmağan süzlär tasvirlama yul belän, şulay uq transliteratsiyä aşa yäki ike alımnı da beryulı qullanıp añlatıldı.

Süzneñ semantikasın tulıraq häm ışandırırlıq itep şärexläw maqsatında qullanılğan ill'ustrativ misallarnı här süzgä yäki anıñ här mäğnäsenä ezlekle kiterü qatğıy şart bulıp tormasa da, avtorlar ul şartnı mömkin qadär ütärgä omtıldılar.

Süzlektä bilgele külämdä başlıça berençe süz prinsıbı belän frazeologizmnarğa, mäqal'-äytemnärgä dä urın birelde. Mömkin bulğanda, alar ikençe ber teldäge täñgälläre aşa añlatıldı, küp kenä oçraqta eçtälege tasvirlama yul belän şärexlände.

Süzlek mäqaläsendäge grammatik, stilistik häm başqa mäğlümatnı qısqa, şul uq waqıtta eçtälekle häm añlayışlı itep tuplaw yözennän, şartlı qısqartılmalar qullanıldı. Alarnıñ isemlege eşlänep, süzlekneñ kereş öleşendä birelde.

Süzlekneñ latin grafikası nigezendä başqarılğan tatarça-inglizçä nösxäsendä baş süzlär «Tatarstan Respublikası däwlät tele bularaq tatar telen qullanu turında»ğı Tatarstan Respublikası Zakonına (2013 yılnıñ 12 yanvare № 1-TRZ) quşımta itep birelgän alfavit tärtibenä turı kiterep urnaştırıldı. Süzlek mäqaläse eçendä andıy tärtip qatğıy saqlanmadı. Transliteratsiyä qağidäläre ayırım eşlänep, tablitsa şäkelendä kereştä urın aldı.

Süzlek kiñ qatlaw qullanuçığa – tatar häm ingliz tellären uqıtuçı belän yäki üzlegennän öyränüçelärgä, bu tellärdä süz baylığın arttırırğa häm belemnären kamilläşterergä teläwçelärgä yärdämçe äsbap bulıp tora. Älege xezmät mäktäp häm yuğarı uqu yortları uqıtuçıları, studentlar, aspirantlar

öçen genä tügel, ingliz telen tuğan tel – tatar tele aşa öyränüçe, şulay uq professional' eşçänlegendä çit teldän faydalanuçılarnıñ härqaysına ğämäli qullanma bula ala. Süzlekneñ tärcemä häm mäğlümat çaraları eşendä dä faydalı çığanaq rolen ütäyäçägenä şik yuq. Dönyanıñ törle qıytğalarında yäşäp, tuğan illären, tuğan tellären sağınıp ğömer kiçerüçe millättäşlärebezgä, ğomumän, tatar tele, tatar dönyası belän qızıqsınğan härkemgä biredä bay häm qızıqlı mäğlümat tabarğa mömkin.

Süzlekne tözüçelär, xezmätne tikşerüdä qatnaşıp, anıñ eçtälegenä qarata häm sıyfatın yaxşırtuğa bäyle töple fiker-täqdimnäre belän urtaqlaşqannarı öçen, Ğ. İbrahimov isem. Tel, ädäbiyat häm sänğät institutınıñ leksikografiyä bülege xezmätkärlärenä, şulay uq kiñäş-tabışları öçen Qazan federal' universitetı möğällimnärenä häm başqa kollegalarğa ixlastan räxmätlären citkerälär.

Avtorlar süzlekneñ eçtälegen, anıñ eşläneşen alğa taba da yaxşırtıp buluwına ışanalar häm uquçılardan alarnıñ şuña yünältelgän fiker-iskärmälären, konstruktiv tänqıyt süzlären tübändäge adresqa yullawların ütenälär:

420111, Qazan şäh., Karl Marks ur., 12 yort, Tatarstan Respublikası Fännär akademiyäse Ğ.İbrahimov isem. Tel, ädäbiyat häm sänğät institutı, leksikografiyä bülege.

Elektron poçta adresı: iyali.anrt@mail.ru

*A.Ä. Timerxanov*